ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ТОЙГУЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ МЕНДЕЛЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
пер. Школьный, д.7,
д. Тойгузино, Менделеевский район,
Республика Татарстан, 423646

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ТОЙГУҖА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Мәктәп тыкрыгы, 7 йорт,
Тойгуҗа авылы, Менделеевск районы,
Татарстан Республикасы, 423646

Тел. (факс): 8(85549) 3-40-13
e-mail: Toyg.Men@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 елның 04 маендагы №5

Хайваннарны хуҗаларыннан башка кайтару тыела торган урыннарны билгеләү һәм хайваннарны хуҗаларыннан башка элеккеге яшәү урыннарына кайтару турында карар кабул итүгә вәкаләтле затлар исемлеген билгеләү турында.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында һәм хайваннар белән җаваплы мөгалләмә турында» 2022 елның 14 июлендәге 269-ФЗ номерлы Федераль законнарга, Менделеевск муниципаль районының Тойгуҗа авыл җирлеге Уставына нигезләнеп, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Тойгуҗа авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Хайваннарны хуҗаларыннан башка кайтару тыела торган урыннар исемлеген әлеге карарга 1 кушымта нигезендә расларга.
2. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Тойгуҗа авыл җирлеге башлыгы Сафин Рафит Әхмәтшин улын терлекләрне элекке яшәү урыннарына хуҗаларыннан башка кайтару турында карар кабул итүгә вәкаләтле зат итеп билгеләргә.
3. Әлеге карарны, Тойгуҗа авылындагы махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштырып таныштырырга, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштырырга һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleeevsk.tatar.ru "Тойгуҗа авыл җирлеге" бүлегендә урнаштырырга.
4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Тойгуҗа авыл җирлеге башлыгы Р.А.Сафин

.

карарына
Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Тойгуҗа авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2023 елның 4 маендагы 5 номерлы
карарына 1 нче кушымта

**Тойгуҗа авыл җирлеге территориясендә хуҗаларыннан башка хайваннарны кайтару тыела торган исемлек**

Хайваннар приютында мондый хайваннарны приютларда, территорияләрдән 500 метр ераклыкта киләчәктә тоту мөмкинлеге булмаган территорияләрдә стерилизацияләү, тамгалау, исәпкә алу, карантинга кую, дәвалау, вакцинация чаралары тәмамланганнан соң, башка хайваннарга яисә кешегә карата мотивлаштырылмаган агрессивлык күрсәтми торган хуҗалардан башка хайваннарны элекке яшәү урыннарына (  аулау оештырылган урынына) кайтару тыела:

- авыл җирлеге администрациясе,
- фельдшер-акушерлык пункты,
- авыл мәдәният йорты
- балалар һәм спорт мәйданчыклары,
- сәүдә объектлары.
- зират.